| | | |
|---|---|---|
| **РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**<br><br>**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ТЮЛЯЧИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА** | | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**<br><br>**ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ** |
| **ПОСТАНОВЛЕНИЕ**<br>«29» июнь 2022 | **с. Тюлячи** | **КАРАР**<br>№ 126 |

Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының
2022 елның 20 апрелендәге 79 номерлы «Опекунга (попечительгә) суд
тарафыннан хокукка сәләтсез яки хокукка сәләте чикләнгән дип танылган
затка караган кредит оешмасындагы счетта булган акчалата чараларны
тотуга, күчерүгә, алуга, счетны ябуга алдан рөхсәт бирү буенча дәүләт
хезмәте күрсәтүнең Административ регламенты»
карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 20 апрелендәге 79 номерлы «Опекунга (попечительгә) суд тарафыннан хокукка сәләтсез яки хокукка сәләте чикләнгән дип танылган затка караган кредит оешмасындагы счетта булган акчалата чараларны тотуга, күчерүгә, алуга, счетны ябуга алдан рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең Административ регламенты» карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) күрсәтелгән карар белән расланган Опекунга (попечительгә) суд тарафыннан хокукка сәләтсез яки хокукка сәләте чикләнгән дип танылган затка караган кредит оешмасындагы счетта булган акчалата чараларны тотуга, күчерүгә, алуга, счетны ябуга алдан рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына:

А) түбәндәге эчтәлекле 1.6 пункт белән тулыландырырга:

«1.6. Муниципаль хезмәтне алдан ук (проактив) режимда күрсәтү очраклары һәм тәртибе.

Мөрәҗәгать итүченең ризалыгы (гарызнамәсе булу) белән муниципаль хезмәт алдан ук (проактив) режимда Республика порталы аша күрсәтелә.

Муниципаль хезмәт күрсәтүне алдан ук (проактив) режимда күрсәтү тәртибе Регламент белән билгеләнә.»;

Б) 2.4 пунктны түбәндәге эчтәлекле абзац белән тулыландырыга:

«Муниципаль хезмәт алдан ук (проактив) режимда күрсәтелгән очракта - Регламентның 1.6 пунктында күрсәтелгән дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтелгән көннән алып 15 эш көне.»;

в) түбәндәге эчтәлекле 2.5 пункты белән тулыландырырга:

«Муниципаль хезмәт алдан ук (проактив) режимда республика порталы ярдәмендә күрсәтелгән очракта:

мөрәҗәгать итүченең муниципаль хезмәт алуга ризалыгы (гарызнамәсе).

Башка документлар бирү таләп ителми. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документлар һәм белешмәләр Башкарма комитет тарафыннан дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен билгеләнгән автоматлаштырылган мәгълүмат системасын кулланып мөстәкыйль алына.

Гариза һәм аңа теркәп бирелә торган документлар гариза бирүче тарафыннан түбәндәге ысулларның берсен кулланып тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин:

- КФҮ аша кәгазь чыганакларда һәм Регламентның 2.5 пункты таләпләре нигезендә имзаланган (таныкланган) электрон документлар рәвешендә;

- Республика порталы аша электрон формада.

Физик затлар һәм шәхси эшмәкәрләр гариза һәм кирәкле документларны республика порталы аша җибәргәндә гаризаны гади электрон имза белән имзалыйлар.

Гади электрон имза алу өчен гариза бирүчегә ЕСИА да теркәлү (аутентификация) процедурасын узарга, шулай ук исәпкә алу язмасын стандарт дәрәҗәсеннән дә ким булмаган дәрәҗәгә кадәр расларга кирәк.

Россия Федерациясе территориясендә теркәлгән юридик затлар һәм юридик затлар вәкилләре гариза һәм кирәкле документларны республика порталы аша җибәргәндә гаризаны көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзалыйлар.

Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документларны тапшырганда, Республика порталы ярдәмендә мөрәҗәгать итүче электрон документлар яки документларны электрон формада, мондый документларны, шул исәптән нотариусларны төзүгә һәм имзалауга вәкаләтле затлар тарафыннан "Электрон имза турында" 2011 елның 06 апрелендәге 63-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләре нигезендә көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган документлар тапшыра.

Гариза бирүчедән түбәндәгеләрне таләп итү тыела:

- муниципаль хезмәт күрсәтүгә бәйле рәвештә барлыкка килә торган мөнәсәбәтләрне җайга салучы норматив хокукый актлар белән тапшыру яки башкару каралмаган документларны һәм мәгълүматны тапшыруны яки гамәлләр башкаруны таләп итү;

- 210-ФЗ номерлы Федераль законның 9 статьясындагы 1 өлешендә күрсәтелгән исемлеккә кертелгән мондый хезмәтләр күрсәтү нәтиҗәсендә күрсәтелә торган хезмәтләрне, шул исәптән муниципаль хезмәт алу өчен кирәкле һәм башка дәүләт органнарына, җирле үзидарә органнарына, оешмаларга мөрәҗәгать итү белән бәйле килешүләрне гамәлгә ашыру;

- муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тартканда яисә муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тартканда

документларның һәм мәгълүматның булмавы һәм (яисә) дөреслеге күрсәтелмәгән документлар һәм мәгълүмат тапшыру, түбәндәге очраклардан тыш:

а) муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза башта бирелгәннән соң муниципаль хезмәт күрсәтүгә кагылышлы норматив хокукый актлар таләпләрен үзгәртү;

б) муниципаль хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән яки муниципаль хезмәтен күрсәтүдән беренче мәртәбә баш тартудан соң муниципаль хезмәтен күрсәтү турында мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылган һәм элегрәк тапшырылган документлар җыелмасына кертелмәгән гаризада һәм документларда хаталар булганда;

в) муниципаль хезмәт күрсәтү өчен яисә муниципаль хезмәт күрсәтүдә кирәкле документларны кабул итүдән баш тартканнан соң документларның гамәлдә булу срогы беткәндә яисә мәгълүматлар үзгәрү;

г) муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән башта баш тартканда йә муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тартканда Башкарма комитет вазыйфаи затының, КФҮ хезмәткәренең хаталы яки хокукка каршы гамәл (гамәл кылмау) фактын (билгеләрен) ачыклау, муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарткан очракта Башкарма комитет җитәкчесе имзасы белән язмача мөрәҗәгать итүчегә хәбәр ителә, шулай ук китерелгән уңайсызлыклар өчен гафу үтенәләр;

д) электрон образлары элек 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясындагы 7.2 пункты нигезендә таныкланган документлар һәм мәгълүматны кәгазь чыганакта бирү, мондый документларга тамга салу йә аларны алу дәүләт яисә муниципаль хезмәт күрсәтүнең кирәкле шарты булып торса, һәм федераль законнарда билгеләнгән башка очраклардан тыш.»;

Г) 2.7 пунктны түбәндәге эчтәлекле абзац белән тулыландырырга:

«Муниципаль хезмәт республика порталында алдан ук (проактив) режимда күрсәтелгән очракта, муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту каралмаган.»;

Д) 2.10 пунктын түбәндәге эчтәлекле абзац белән тулыландырырга:

«Теләче муниципаль районы Советының 2011 елның 11 июлендәге 52 номерлы «Муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүдә катнашучы һәм аларны күрсәткән өчен түләүнең иң чик күләмен билгеләүче оешмалар тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләр исемлеген раслау турында» карары» ;

Е) 3 пунктның исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Административ процедураларның составы, эзлеклелеге һәм сроклары, аларны үтәү тәртибенә карата таләпләр, шул исәптән электрон формада административ процедураларны үтәү үзенчәлекләре, шулай ук күпфункцияле үзәкләрдә административ процедураларны башкару үзенчәлекләре. Бүлектә күрсәтелгән хезмәтләрне күрсәтүнең гомуми билгеләре белән берләшкән мөрәҗәгать итүчеләрнең аерым категорияләренә, шул исәптән дәүләт хезмәте нәтиҗәсенә карата да, күрсәтелгән хезмәтләрне күрсәтү тәртибен үз эченә алган дәүләт хезмәте күрсәтү вариантлары бар.»;

Ж) 3.4.1 пунктын түбәндәге эчтәлекле абзац белән тулыландырырга:

«Муниципаль хезмәт Республика порталы ярдәмендә алдан ук (проактив) режимда күрсәтелгән очракта, ведомствоара гарызнамәләр юнәлтү гамәлгә ашырылмый.

Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле белешмәләр Регламентның 2.6 пунктында каралган тәртиптә дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен билгеләнгән автоматлаштырылган мәгълүмат системасыннан файдаланып алына.».

2. Әлеге карар гамәлдәге законнар нигезендә үз көченә керә.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Җитәкче урынбасары – Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты территориаль үсеш бүлеге башлыгы Б.Г. Гайнетдиновка йөкләргә.

Җитәкче И.Х. Хәмидуллин